РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«15» 06 2020 ел №375

Гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу
ихтималы очрагында Ютазы муниципаль
районы халкын вакытлыча урнаштыру
пунктларын оештыру турында

"Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында" 21.12.1994 ел, № 68-ФЗ Федераль закон нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законга, РФ Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 25.12.2013 ел, № 2-4-87-37-14 боерыгы белән расланган Гадәттән тыш хәлләрдә халыкның беренче чиратта тормышын тәэмин итүне оештыру һәм зыян күргән халыкны вакытлыча урнаштыру пунктларының эшен оештыру буенча методик рекомендацияләргә таянып, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр ихтималы һәм барлыкка килү зонасына эләккән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы халкын вакытлыча күчерү (урнаштыру) чараларын планлаштыру, тәэмин итү, медицина ярдәме күрсәтү, җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм саклау бурычларын үтәү максатында

карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда халыкны вакытлыча урнаштыру пункты турында Нигезләмәне расларга (кушымта №1)

2. Урман янгыннары куркынычы һәм язгы ташу чорында су басу куркынычы янаган торак пунктларда яшәүчеләрне вакытлыча урнаштыру пунктлары исемлеген расларга (кушымта №2)

3. Урман янгыннары куркынычы һәм язгы ташу чорында су басу куркынычы янаган торак пунктларның авыл җирлекләре башлыкларына:

- пунктлар администрациясе составын расларга, пунктларның оештыру-боеру документларын эшләргә һәм килештерергә;
- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлеге белән вакытлыча урнаштыру пунктларында җәмәгать тәртибен саклау һәм тәэмин итү өчен билгеләнә

торган хезмәткәрләрнең санын, эш срокларын килештерергә;

- “Урыссу үзәк хастаханәсе» ДАССО белән вакытлыча урнаштыру пунктларында халыкны медицина һәм психологик ядәмне оештыруны килештерергә, аларда медицина персоналының тәүлек буе кизү торган медицина пунктларын җәелдерүгә әзерлек белән алдан планлаштырырга;

4. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлегенә:

- аларда бер тәүлек эчендә урнаштырыла торган кешеләрнең суммар күләменнән чыгып, зыян күргән халыкны вакытлыча урнаштыру пунктларында урнаштыру өчен кирәкле азык-төлек, эчәргә яраклы су, йокы кирәк-яраклары һәм беренче чиратта кирәкле товарларга алдан исәп-хисап ясарга;

- оештыру-хокукый формасына һәм милек төренә бәйсез рәвештә, предприятиеләр, оешмалар белән өч тапкыр кайнар ризык белән тәэмин итүне, азык - төлек һәм матди-техник чаралар алып килүне оештыру буенча шартнамәләр төзергә.

5. Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының «Янгын куркынычы янаган чорда Ютазы муниципаль районы халкын вакытлыча урнаштыру пунктларын оештыру турында» 25.05.2011 ел, № 326 карары үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге карарны «Ютазы таңы» («Ютаинская новь») район газетасында, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми бастырып чыгару юлы белән урнаштырырга, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

7. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктураны үстерү буенча урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы Башкарма
комитеты җитәкчесе А. Ә. Шафигуллин

Р. Ә. Шәрипов
8(85593) 2-79-36

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль
районы Башкарма
комитеты җитәкчесе
карарына
№ _ «___» ______2020 ел

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу очрагында халыкны вакытлыча урнаштыру пункты турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

**1.Гомуми нигезләмәләр.**

Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә гадәттән тыш хәл (алга табан – ГТХ) куркынычы булганда яки килеп чыккан очракта эвакуацияләнә торган халыкны вакытлыча урнаштыру пунктларының төп бурычларын, оештыру һәм эшләү тәртибен билгели.

Зыян күргән халыкны вакытлыча урнаштыру пункты (алга таба – ПВР, пункт) гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасының территориаль ярдәмче системасының район звеносы элементы булып тора.

Гадәттән тыш хәлләрдә зыян күргән халык өчен вакытлыча урнаштыру пунктлары булдыруның төп максаты - кешеләрнең гомерен һәм сәламәтлеген саклау өчен шартлар тудыру. Гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканнан соң, бу, оештыру ягыннан иң катлаулы чор.

Зыян күргән халыкны вакытлыча урнаштыру пункты гадәттән тыш хәл ихтималы булган яисә гадәттән тыш хәлләр зонасыннан чыгарылган халыкны кабул итү, вакытлыча урнаштыру, исәпкә алу һәм халыкны беренче чиратта тормыш белән тәэмин итү өчен билгеләнгән.

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә гадәттән тыш хәл килеп туган очракта эвакуацияләнә торган халыкны вакытлыча урнаштыру пункты эшчәнлеге Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районының норматив хокукый актлары һәм әлеге Нигезләмә белән билгеләнә.

**2.Вакытлыча урнаштыру пунктының төп бурычлары булып тора:**

а) көндәлек эшчәнлек режимында:

- гадәттән тыш хәлләр (гадәттән тыш хәл ихтималы булган) зоналарыннан чыгарыла торган халыкны оешкан кабул итү буенча чараларны планлаштыру һәм гамәлләргә әзерлек;

- кирәкле документлар эшләү;
- биналарны, инвентарьны, элемтә чараларын вакытында әзерләү һ. б.;
- зыян күргән халыкны кабул итү, исәпкә алу һәм урнаштыру буенча вакытлыча урнаштыру пункты администрациясен өйрәтү;
- өйрәнүләр һәм тренировкалар барышында халыкны вакытлыча урнаштыру администрациясенең хәбәр итү, җыю һәм функцияләштерү мәсьәләләрен гамәли эшләү;
- Ютазы муниципаль районы буенча Татарстан Республикасы ГТХМ, КЧС ПБ, Татарстан Республикасы муниципаль районының эвакуация комиссиясе үткәргән өйрәнүләрдә, тренировкаларда һәм тикшерүләрдә катнашу.

б) гадәттән тыш хәл режимында:

- вакытлыча урнаштыру пунктын тулы җәелдерү, халыкны кабул итүгә һәм урнаштыруга әзерлек;
- килүче халыкны исәпкә алуны оештыру һәм аны урнаштыру;
- район эвакуация кабул итү комиссиясе (алга таба - РЭК), Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Ютазы муниципаль районы буенча бүлеге, муниципаль районның ПБ һәм Татарстан Республикасының коткару хезмәтләре белән элемтә урнаштыру;
- халыкның беренче чиратта яшәешен тәэмин итүне оештыру;
- вакытлыча урнаштыру пунктына килүче кешеләр өчен шартлар турында мәгълүмат;
- Ютазы муниципаль районының эвакуация кабул итү комиссиясенә халыкны кабул итү һәм урнаштыру барышы турында докладлар, донесениеләр тапшыру.
- эвакуацияләнгән халыкны озак яшәү пунктларына озатуга әзерләү.

## 3. Вакытлыча урнаштыру пункты администрациясе составы.

| | |
|---|---|
| - ПВР начальнигы | 1 кеше |
| - комендант | 1 кеше |
| - очрашу, кабул итү, теркәү һәм урнаштыру төркеме | 2 кеше |
| - җәмәгать тәртибен саклау төркеме | 2 кеше |
| - медпункт | 1 кеше |
| - туклану пункты | 1 кеше |

Вакытлыча урнаштыру пункты начальнигы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы авыл җирлеге башлыгы карары белән билгеләнә.

Калган состав ПВР башлыгы боерыгы белән билгеләнә, аңа ПВР җәелдерү йөкләнә.

ПВР эше өчен гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация чараларын тәэмин итүдә катнашучы оешманың көчләре һәм чаралары бирелә:

- жәмәгать тәртибен саклау хезмәтеннән: 2 хезмәткәр һәм транспорт - жәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү һәм ПВР урнашкан районда хәрәкәтне җайга салу өчен тавышлы элемтәсе булган транспорт;
- медицина хезмәте бүлегеннән (якын-тирә медицина учреждениеләре арасыннан): урта медицина персоналы (1 кеше) – вакытлыча урнаштыру пунктында медицина пунктын оештыру өчен;
- сәүдә һәм туклану хезмәтеннән: бер вәкил, шулай ук чаралар һәм персонал (якын - тирә сәүдә һәм җәмәгать туклануы оешмалары арасыннан) - туклану пунктын ачу һәм зыян күргән халыкны беренче чиратта кирәкле әйберләр белән тәэмин итү өчен.

## 4. Вакытлыча урнаштыру пункты эшен оештыру.

Зыян күрүче халыкны вакытлыча урнашу пункты җәелдерелгән оешманың җитәкчесе документлар эшләүне, пункт эше өчен кирәкле матди-техник тәэмин ителешне оештыра, ПВР администрациясен гамәли укытуны оештыра һәм пункт әзерлеге өчен шәхси җаваплылык тота.

Пункт эшен регламентлаучы төп документ булып әлеге Нигезләмә тора. Үз эшчәнлегендә вакытлычап урнаштыру пункты администрациясе районның гадәттән тыш хәлләр һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү коммисиясенә буйсына, ә эвакуация чараларын үтәгәндә - Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының эвакуация комиссиясенә һәм эвакуация чараларын үткәрүдә катнашучы оешмалар белән хезмәттәшлек итә.

Пункт эшен оештыру максатларында аның администрациясе тарафыннан түбәндәге документлар эшләнә:
- пункт оештыру турында оешма җитәкчесе боерыгы;
- пункт администрациясенең функциональ бурычлары;
- пункт администрациясенең штат-вазыйфаи исемлеге;
- пункт администрациясе гамәлләренең календарь планы;
- пункт администрациясенә хәбәр итү һәм җыю схемасы;
- эвакуацияләнә торган халыкны вакытлыча урнаштыру пунктына урнаштыру планы;
- элемтә һәм пункт белән идарә итү схемасы;
- пунктка эвакуацияләнә торган халыкны теркәү журналы;
- вакытлыча урнаштыру пунктында алынган һәм бирелгән күрсәтмәләр, хәбәрләр (донесениеләр) һәм докладлар журналы;

Вакытлыча урнаштыру пункт эшчәнлеген тәэмин итү өчен шулай ук мөһим:
- пункт элементларының урнашу һәм эвакуацияләнүчеләрнең хәрәкәт итү күрсәткечләре;
- ГО хәбәр итү сигналлары исемлеге һәм алар буенча гамәлләр тәртибе;
- электр фонарьлары;

- электромегафоннар;
- биналарны һәм территорияне җыештыру өчен инвентарь.

Вакытлыча урнаштыру пункты администрациясенең барлык шәхси составы күкрәкләрендә вазыйфасы, фамилиясе, исеме һәм әтисенең исеме күрсәтелгән бирка булырга тиеш.

Барлык биналар һәм ПЭП янындагы бөтен территория яхшы яктыртылырга тиеш.

1. Вакытлыча урнаштыру пункты (пункт) начальнигы документлары:
- пункт начальнигының функциональ бурычлары;
- гадәттән тыш хәлләрдә зыян күргән халыкны вакытлыча урнаштыру хезмәте күрсәтүгә шартнамә;
- пункт шәхси составына хәбәр итү схемасы;
- пункт шәхси составы исемлеге;
- пункт элементларын урнаштыру схемасы;
- пункт начальнигы таныклыгы;
- пункт администрациясенең функциональ бурычлары;
- телефон белешмәлеге.

2. Эвакуацияләнгән халыкны теркәү һәм исәпкә алу төркеме документлары:
- вакытлыча урнаштыру пунктында эвакуацияләнә торган халыкны теркәү журналы;
- телефон белешмәлеге;
- функциональ бурычлар.

3. Медицина пункты документлары:
- медицина ярдәме сорап мөрәҗәгать иткән эвакуацияләнүчеләрне теркәү журналы, шулай ук Россия Сәламәтлек саклау министрлыгы боерыклары белән регламентланган башка документлар.

4. Белешмәләр өстәле документлары:
- вакытлыча урнаштыру пунктының алынган һәм бирелгән күрсәтмәләре, донесениеләре һәм докладлары журналы;
- телефон белешмәлеге.

Вакытлыча урнаштыру пункты начальнигы тарафыннан вакытлыча урнаштыру пунктын ачуга күрсәтмәләр алгач, вакытлыча урнаштыру пункты администрациясе гамәлләренең календарь планы нигезендә чаралар башкаралар.

Эвакуацияләнә торган халыкны урнаштыру оешма бинасында, аның матди-техник чараларын һәм җиһазларын кулланып башкарыла. Кирәк булган очракта, объект Ютазы муниципаль районы башлыгы карары буенча вакытлыча туктатыла.

Сәүдә һәм туклану хезмәте тарафыннан җәелдерелгән туклану пунктын урнаштыру һәм оештыру өчен гамәлдәге ашханә бинасы һәм ярдәмче бүлмәләр бирелә.

Медицина пунктын һәм районның медицина хезмәте тарафыннан җәелдерелә торган психологик тәэмин итү бүлмәсен урнаштыру өчен

вакытлыча урнаштыру пункты начальнигы аерым бүлмәләр бирә.

Эвакуацияләнә торган халыкны тормыш белән тәэмин итү буенча барлык сорауларны вакытлыча урнаштыру пункты башлыгы гадәттән тыш хәлләр һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының эвакуация комиссиясе белән бергә хәл итә.

Халыкны вакытлыча урнаштыру, шул исәптән матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын куллануга чыгымнар җирле үзидарә органнары һәм оешмалар тарафыннан тотылган чыгымнар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә каплана.

2 нче кушымта
Татарстан
Республикасы Ютазы
муниципаль районы
Башкарма комитеты
җитәкчесе карарына
№ __ _ "__"___2020ел

ИСЕМЛЕК
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы халыкны
вакытлыча урнаштыру пунктлары исемлеге

| № т/б | Учреждение исеме | Оешма, учреждение адресы, телефон номеры. | Пункт начальнигы, вазыйфасы |
|---|---|---|---|
| 1. | Әбсәләм авылы мәдәният йорты | Ютазы районы, Әбсәләм авылы, Совет ур., 50 4-24-07 | Директоры: Миңнуллин Малик Марат улы |
| 2. | “Ютазы урта мәктәбе» МББУ; | Ютазы районы, Ютазы авылы, Комсомол ур., 2 йорт 4-02-00 | Директоры: Ямалетдинов Әнис Әнвәр улы |
| 3 | Ютазы авылы мәдәният йорты | Ютазы районы, Ютазы авылы , Дмитров ур., 9 4-00-67 | Директоры: Хөббәтуллин Рәшит Миңнегалим улы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4 | Кәрәкәшле авылы мәдәният йорты | Ютазы районы, Кәрәкәшле авылы ,<br>М. Зәкиев ур.,<br>4-21-06 | Директоры:<br>Исхакова Эльвира Фатыйх кызы |
| 5 | Бәйрәкә авылы мәдәният йорты | Ютазы районы, Бәйрәкә авылы ,<br>Октябрь ур., 1а<br>6-25-28 | Директоры:<br>Михайлова Гөлнәзирә Ильяс кызы; |
| 6 | Иске Урыссу авылы мәдәният йорты | Ютазы районы, Иске Урыссу авылы, Совет ур., 45а<br>4-42-98 | Директоры:<br>Садыйкова Раилә Раил кызы |
| 7 | Бәйрәкәтамак авылы мәдәният йорты | Ютазы районы, Бәйрәкәтамак авылы, Яңа ур., 36<br>5-13-06 | Директоры:<br>Гыйльметди нова Фирдәүсә Мәсәлим кызы |
| 8 | Димтамак авылы мәдәният йорты | Ютазы районы, Димтамак авылы, Яңа ур., 4в<br>4-52-37 | Директоры:<br>Таймолкина Марина Валентиновна |
| 9 | Акбаш авылы мәдәният йорты | Ютазы районы, Акбаш авылы,<br>Мәктәп урамы 17<br>4-14-34 | Директоры:<br>Газизуллина Резидә Мөдәррис кызы |